ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АПАС МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ СОВЕТЫ

КАРАРЫ

2023 ел, 11 декабрь №221

Татарстан Республикасы Апас муниципаль районында муниципаль хезмәт турында нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

"Муниципаль хезмәт турында Татарстан Республикасы кодексының 10 статьясына үзгәрешләр кертү хакында" 2023 елның 2 ноябрендәге 99-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә Татарстан Республикасы Апас муниципаль районы Советы карар итте:

1.Татарстан Республикасы Апас муниципаль районы Советының 2023 елның 30 гыйнварындагы 152 номерлы “Татарстан Республикасы Апас муниципаль районында муниципаль хезмәт турында нигезләмәне раслау турында” карарына түбәндәге үзгәреш кертергә:

1) 4.13 пунктта икенче җөмләне төшереп калдырырга;

2) 4.19 пунктны үз көчен югалткан дип танырга;

3 4.21 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"4.21.Муниципаль хезмәткәргә класс чины бирү турындагы карар, әлеге нигезләмәнең 4.15 пунктында күрсәтелгән очраклардан тыш, класс чины бирү хакында тәкъдим барлык кирәкле документлар белән бергә җирле үзидарәнең класс чиннары бирергә вәкаләтле органына яисә вазыйфаи затына кергән көннән алып бер айдан да соңрак булмаган срокта кабул ителергә тиеш. ".

2.Әлеге карарны Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында бастырырга.

3.Бу карарның үтәлешен контролләүне Башлык урынбасары Л.Т. Хантимировка йөкләргә.

Татарстан Республикасы Апас муниципаль районы башлыгы-
Татарстан Республикасы Апас муниципаль районы Советы Рәисе- А.Г. Җиһаншин